# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
## Сукаеш авыл җирлеге Советы

Зур Сукаеш авылы № 26 «18» октябрь 2019 ел.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының кайбер норматив актларын юкка чыгару турында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының 18.10.2019 ел № 26 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карары кабул ителү сәбәпле, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы

Сукаеш авыл җирлеге Советы карар чыгара:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советы карарларын гамәлдән чыгарырга:

- № 22 19.09.2019 ел. «Референдум үткәрү инициативасы турында»;
- № 23 20.09.2019ел. «Сукаеш авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Рәис Закирова З.Җ.